М. М. Шәкүрова, Л. М. Гыйниятуллина, О. Р. Хисамов

# Туган тел
## (ТАТАР ТЕЛЕ)

### 2 сыйныф

МЕТОДИК ӘСБАП

*Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен*

КАЗАН
2020

УДК 811.512.145 (075.2)
ББК 81.632.3я71
Ш92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләнде

**Шәкүрова, М. М.**

Ш92 Туган тел (татар теле). 2 сыйныф. Методик әсбап : башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән) эшләүче укытучылар өчен. / М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов. — Казан, 2020. — 38 б.

Методик әсбапта 2 сыйныфта программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр, материалның эчтәлеге бирелә, дәреслек белән эшләү тәртибе аңлатыла. Тематик планда ике юнәлеш өчен булган фонетик, лексик, грамматик материал, укучыларның эшчәнлек төрләре, аларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә куелган таләпләр карала.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Г. Ибрагимов исем. ТӘһСИ, 2020
© М.М. Шәкүрова, Л.М. Гыйниятуллина, О.Р. Хисамов, 2020

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Укыту-методик комплекты татар телен туган тел буларак өйрәнә торган 2 сыйныф укучылары белән эшләүче укытучыларга тәкъдим ителә. УМК үз эченә уку әсбабы, электрон дәреслек, аудиоязмалар дискы һәм укытучылар өчен методик әсбапны ала.

Әлеге методик әсбапта икенче сыйныф өчен әзерләнгән уку әсбабы белән эшләү тәртибе, структурасы, темаларның төзелеше, күнегү төрләре аңлатыла, «Туган тел (татар теле)» предметының эчтәлеге, өйрәнелергә тиешле лексик, грамматик материал ачыклана, Тематик план һәм кайбер дәресләрнең үрнәк планнары тәкъдим ителә.

Урта (тулы) гомуми белем бирү оешмаларының башлангыч белем бирү этабында «Туган тел (татар теле)» предметы Федераль дәүләт белем бирү стандартларында күрсәтелгән гомуми белем бирү нәтиҗәләренә куелган таләпләргә туры китерелеп укытыла. «Туган тел (татар теле)» предметыннан белем бирүнең сыйфатын арттыру, теоретик материалны аңлату барышында, тирән белем бирү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уяту һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга, язарга, фикерләргә өйрәтү таләп ителә.

2 сыйныфта «Туган тел (татар теле)» предметын укыту түбәндәге максатларны тормышка ашыруга юнәлтелә:

- укучыларда коммуникатив компетенция формалаштыру. Сөйләм мөмкинлекләреннән чыгып, туган телдә телдән һәм язмача аралашырга өйрәтү;
- балалар әдәбиятын, тарихын, фольклор әсәрләрен өйрәнү аша татар мәдәниятенә карата ихтирам хисләре тәрбияләү.

Әлеге максатларны тормышка ашыру өчен куелган бурычлар:

- Татарстан Республикасында төрле милләтләрнең үзара аралашу чарасы буларак, татар теле турында мәгълүмат бирү;
- сөйләмә һәм язма телне үстерү максаты белән телнең грамматик нигезләрен үзләштерү;
- тел материалын үзләштерү барышында, аралашу очракларында, рольле уеннарда укучының шәхси сыйфатларын, игътибарын, фикерләү сәләтен, хәтерен һәм иҗадилыгын үстерү;
- предметка карата кызыксыну, уңай мотивация, туган телне өйрәнүгә мөмкинлек бирә торган махсус универсаль уку гамәлләре формалаштыру.

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

### Уку әсбабының структурасы

Уку әсбабы ике кисәктән тора. Һәр кисәк ике зур теманы үз эченә ала. Беренче кисәктә «Мин» һәм «Тирә-як, көнкүреш» темаларын, икенче кисәктә «Туган җирем» һәм «Татар дөньясы» темаларын өйрәнү өчен материал бирелә.

### Темаларның төзелеше

Һәр тема бертөрле калыпка ия. Темалар икедән алып бишкә кадәр дәресне үз эченә ала.

1) Укучылар ярдәме белән тема әйтелә.
2) Кагыйдә тәкъдим ителә.
3) Ныгыту өчен биремнәр эшләнә.
4) Парларда эш.
5) Куян күчтәнәчендә бireләчәк теориягә якын килү.
6) Куян күчтәнәче.

7) Куян күчтәнәчен ныгыту өчен биремнәр.

8) Теманы йомгаклау өчен күнегүләр, логик биремнәр, кызыклы эш төрләре.

Уку әсбабы ике юнәлешне (база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне) үз эченә ала. Туган телне тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган материал зәңгәрсу фон белән бирелде. Әмма база өлешен өйрәнә торган укучылар белән эшләүче укытучылар, балаларның белем дәрәҗәләреннән, мөмкинлекләреннән чыгып, әлеге биремнәрне дә эшли алалар. Ике юнәлешнең бер китапта бирелүе көчлерәк укучылар белән аерым якын килеп эшләү мөмкинлеге тудыра.

## Уку әсбабындагы күнегү төрләре

*«Рольләргә бүлеп укы»* биреме ике юнәлеш өчен булган материалны берләштерә. База өлешен өйрәнүчеләргә диалог геройлар әңгәмәсе формасында тәкъдим ителә. Геройлар санына карап, репликалар төсле рамкаларда бирелә. Укучыга үзе укырга тиешле сүзләрне күрергә уңайлы. Биремне диалог тексты белән эшләү өчен булган эш төрләре дәвам итә.




1) Ләйләнең портфелен кем тутыра?
2) Икенче сыйныфта портфельгә ике килограмм әйбер салырга ярый. Синең сумкада әйбер күпме?

Икенче төр диалоглар — тирәнтен өйрәнүчеләр өчен. Алар зәңгәрсу фон эченә урнаштырылды. Диалог белән эшне төрле биремнәр йомгаклый.



— Хәерле көн, Тимерхан!
— Хәерле көн, Таңсылу! Син кичә урманга бардыңмы?
— Әйе, әни, әти һәм Акбай белән урманга бардым. Мин урманда адаштым.
— Курыктыңмы?
— Бик курыктым. Акбай мине тиз эзләп тапты.

1) Таңсылу кайда адаша?
2) Аны урманда ничек табалар?
3) Әгәр зур кибеттә адашсаң, нәрсә эшлисең?

Кайбер дәресләрдә авторларның әсәрләре диалог буларак тәкъдим ителә.

**Рольләргә бүлеп укы.**
Рабит Батулланың «Елак әтәч» әкиятеннән диалогны сәхнәләштер.



— Нигә елыйсың, Әтәчкәй?



— И-и-и, томшыгым авырта. Йоклый алмыйм. Ашый алмыйм.

— Тешләрең кая, Әтәчкәй?

— Конфет күп ашадым. Мин шоколад яратам.

**томшык** — клюв

- Диалог ярдәмендә әкиятнең эчтәлеген сөйлә.
- Әтәчнең тешләре ни өчен төшә?

Нәкыйп Каштановның «Безнең сыер» шигырен рольләргә бүлеп укы.

— Әби, әби, әйт әле:
Сыер нигә мөгери?
— Ашыйсы килгән, улым,
Печән китер, йөгер, — ди.
— Ашап туйгач, ник сыер
Сузып-сузып «му-у» ди ул?
— Эчәсе килгән, улым,
«Китер миңа су-у!» — ди ул.



- Каштанов Н., Батулла Р. Исемлектә кайсы автор беренче булыр? Ни өчен?
- Җөмләләрне язып бетер.




*Сыер ______ ашый. Ул ______ эчә.*
*Сыер безгә ______ бирә.*

Уку әсбабында татар халык авыз иҗаты әсәрләренә күп игътибар бирелде. Әкиятләр, санамышлар, табышмаклар, мәкальәйтемнәр текстлары ярдәме белән, өйрәнелә торган фонетик, лексик һәм грамматик материалга караган биремнәр эшләнә. Бу эш төрләре, бердән, укучының фикерләү, уйлау сәләтен камилләштерергә булыша, икенчедән, өйрәнелә торган лексик берәмлекләрне истә калдырырга мөмкинлек бирә.

**5. Укы.** Санамыштан ике иҗекле сүзләрне табып әйт.

Бер, ике, өч, дүрт, биш,
Алты, җиде, сигез, тугыз, ун.
Байлар кия төлке тун.
Төлке тунның бәясе
Бер йөз кырык ике сум.



**22.** **Мәкальләрнең башы белән ахырын парлап укы.**
Антоним сүзләрне тап.

| | |
|---|---|
| Былтыр кысканга | кыш ашыйсың. |
| Жәй эшлисең, | дошман алдында мактый. |
| Дус артында мактый, | быел кычкырмыйлар. |

*«Күчереп яз», «Җөмләне язып бетер»* биремнәре укучыларда хатасыз, матур язу күнекмәләрен формалаштыру өчен тәкъдим ителә.

*«Хаталы җөмләләрне тап», «Сүзләргә төшеп калган кушымчаларны ялгап укы», «Иҗекләрдән яңа сүзләр төзе», «Төшеп калган сүзләрне куеп, шигырьне укы», «Җөмләләр төзеп яз»* кебек биремнәр укучыларның телдән һәм язма сөйләмен камилләштерергә, сүз байлыгын арттырырга, сөйләмнәренә яңа лексик берәмлекләр кертергә булыша.

Дәресләрдә текст белән эш үзәктә тора. Текст белән эшләгәндә, укытучы аның авторына, текстның геройларына, эчтәлегенә игътибарны юнәлтергә тиеш.

Туган тел (татар теле) дәресләрендә тәрҗемә күнекмәләрен формалаштыру, ныгыту юнәлешендә дә эш алып барылырга тиеш. Моның өчен уку әсбабында *«Сүзләрне тәрҗемәләре белән парлап укы», «Татарчага тәрҗемә ит»* кебек биремнәр урнаштырылды.

*«Русча-татарча сүзлек ярдәмендә башваткычны чиш»* кебек биремнәр, тәрҗемә күнекмәләре формалаштырудан тыш, төрле сүзлекләр белән эшләргә дә өйрәтә.

**69.** **Русча-татарча сүзлек ярдәмендә башваткычны чиш.**



1. Сказка.
2. Поэт.

1. Рассказ.
2. Стих.
3. Книга.

**1.** **Аңлатмалар ярдәмендә сүзләрне тап.**




1. Кече яшьтәге ир бала.
2. Укырга өйрәтә торган дәреслек.
3. Әдәби әсәрдәге төп персонаж.
4. Шук, шаян.
5. Тылсымлы көчләр, сихерчеләр турындагы әсәр.

1) Башваткычтагы сүзләрне табарга нәрсә булышты?
2) Һәр сүз мәгънә белдерәме?

Уку әсбабында төрле төсләр белән эшләнгән таблицалар бар. Алар укучыларга җавапны тиз табарга булыша. Материал шулай ук ике юнәлешне дә исәпкә алып бирелә.

**58. Дәресләрдә укыган текстларны искә төшер.** Яхшы дус булган парларны әйт. Фикереңне аңлат.

| | + | − |
|---|---|---|
| Закир һәм Равил | + | Равил Закирга өй эшен аңлата. |
| Закир һәм Зөфәр | | |
| Торна һәм Төлке | | |
| Куян һәм Кыңгырау чәчәк | | |
| Камал һәм Җәмил | | |
| Камал һәм Таһир | | |
| малай һәм сеңлесе | | |
| Хәмит һәм Илһам | | |
| Әтәч һәм Бөркет | | |
| Һади һәм Җәвит | | |
| Аю һәм Бабай | | |

Уку әсбабында урын алган төрле башваткычлар, конкурслар укучыларның белемнәрен ныгытырга, тәрҗемә күнекмәләрен формалаштырырга, логик фикерләү сәләтен үстерергә ярдәм итә.

- Песи баласына [w], [ғ], [қ], [в], [г], [к] авазлары кергән кушаматлар уйла. «Иң яхшы кушамат» конкурсы уздырыгыз.



Төрле биремнәр, рәсемнәр ярдәмендә укытучы әдәби әсәрләргә һәм аларның авторларына, геройларына игътибар юнәлтә ала.

● Автор белән шигырь исемен парлап укы.

| | |
|---|---|
| Җәвад Тәрҗеманов | «Тәмле тамаклар» |
| Роберт Миңнуллин | «Безнең гаилә» |
| Гөлшат Зәйнашева | «Якын дус» |
| Хәкимҗан Халиков | «Бер атнада ничә көн?» |

**66. Рәсемнәрне игътибар белән кара.**



1) Бу малайның исеме Камилме? Аның исеме ничек?



2) Бу кем? Ул Шүрәле белән дусмы?



3) Бу Актырнакмы? Аның кушаматы ничек?



4) Бу кайсы әкият герое? Алтын таракны кем урлый? Ул дөрес эшлиме?

Уку әсбабында 1 уен тәкъдим ителә.

**66–67 битләрдәге уен.** Укучы үзенең берәр предметын йөреш өчен куллана ала. Балалар, Булат исемле малайга дусты Тимерхан янына барып җитәргә булышу өчен, өч бирем эшләргә тиеш. Шул ук вакытта укытучы ярдәме белән юл йөрү кагыйдәләре дә искә төшерелә. Биремнәрне хаталарсыз беренче булып эшләгән укучы җиңүче була.

Өйрәнгән темаларны кабатлау өчен, уку әсбабында «Текст белән эш» һәм «Кабатлау» дәресләре бар.

«Текст белән эш» дәресендә укучылар аудиотекст тыңлыйлар. Текстка карата сорауларга җавап бирәләр. Алга таба укучылар әлеге текстны укыйлар, аның ярдәмендә өйрәнелгән материал ныгытыла.

«Кабатлау» дәресе дә шундый ук төзелешкә ия. Биредә уку материалы сөйләм эшчәнлеге төрләренә караган ныклы күнекмәләр булдыруны күздә тота.

# ТУГАН ТЕЛ «ТАТАР ТЕЛЕ» ПРЕДМЕТЫНЫҢ ЭЧТӘЛЕГЕ

Дәреслек дүрт лексик теманы үз эченә ала.

**«Мин»** темасында укучының мәктәптәге һәм өйдәге тормышы, үз-үзен тотышы, баланың көндәлек режимы, көн дәвамында нәрсәләр эшләве, гаилә, гаиләдәге мөнәсәбәтләр, дуслык турында сөйләшү, текстлар белән эшләү, әңгәмәләр кору күз алдында тотыла.

**«Тирә-як, көнкүреш»** темасы кысаларында төрле халык әкиятләре, әкият геройлары турында сөйләшү алып барыла. Укучылар геройларны чагыштырып сөйлиләр, язма һәм сөйләм телләрен камилләштерәләр.

**«Туган җирем»** темасын өйрәнгәндә укучылар җәмәгать урыннарында үзеңне ничек тотарга кирәклеге турында мәгълүмат туплый. Урманнар, хайваннар дөньясын сакларга кирәклеге турында әңгәмә кора.

**«Татар дөньясы»** темасында каз өмәсе, Нәүруз бәйрәме турындагы текстлар белән эшләп, укучыларның сөйләм теле баетыла.

**Фонетика. Орфоэпия.** Татар теленең сузык авазлар һәм тартык авазлар системасы. Сузык авазлар һәм тартык авазларның саны. Калын һәм нечкә сузыклар. Парлы һәм парсыз сузыклар. Татар теленең үзенчәлекле авазлары: [ә], [ө], [ү], [w], [ғ], [қ], [җ], [ң], [һ].

[ō], [ы̄], [э̄] сузык авазлары. Татар телендә [в] авазының кулланылуы. [г], [к], [ғ], [қ] авазларының кулланылу үзенчәлекләре. Борын авазлары. Интонация.

**Графика.** [ә], [ө], [ү], [w], [ғ], [қ], [җ], [ң], [һ] авазларын язуда белдерә торган хәрефләр. Е, ё, ю, я хәрефләре. Аваз белдерми торган хәрефләр (ъ, ь). Җөмләнең беренче сүзен, ялгызлык исемнәрне баш хәрефтән язу.

**Лексика.** Сүз. Сүзнең лексик мәгънәсе. Антонимнар, синонимнар. Сөйләмдә синонимнарны һәм антонимнарны куллану.

Контексттан чыгып яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә сүзнең мәгънәсен билгеләү.

Лексик мәгънәләренә карап, сүзләрне төркемләү. Синонимнар рәте. Синонимнарның әкиятләрдә кулланылуы.

**Морфемика.** Татар телендә сүзләргә кушымчалар ялгану үзенчәлеге.

*-кай/-кәй* кушымчасының мәгънәсе. *-лы/-ле, -сыз/-сез* кушымчалары ярдәмендә ясалган антонимнар. *-ла/-лә* кушымчасы ярдәмендә фигыль ясалу. Калын сузыклар да, нечкә сузыклар да булган сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлеге.

**Морфология.** Мөстәкыйль сүз төркемнәре.

Исем сүз төркеме. Баш хәрефтән языла торган сүзләр. Исемдә сан категориясе. Борын авазларына беткән сүзләргә күплек сан кушымчасы ялгау.

Ялгызлык исемнәр. Рус телендә күплек саны гына булган исемнәрнең татар телендә кулланылуы.

Сыйфат. Сыйфат ясагыч кушымчалар. Сыйфатларның җөмләдәге роле.

Сыйфатларның сөйләмдә кулланылуы.

Фигыль. Гомуми мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылуы. Хәзерге заман хикәя фигыль.

**Синтаксис.** Сүз һәм җөмләне аеру. Әйтелү максатына карап җөмлә төрләре: хикәя, сорау һәм тойгылы җөмләләр.

«Нишли?» соравына җавап биргән сүзнең җөмләдәге урыны. Стиль хаталары: кабатлаулар.

**Графика һәм орфография.** Алфавит. Сүзлек, белешмә, каталоглар белән эшләгәндә алфавиттан файдалану. Тартык һәм сузык авазларны белдергән хәрефләрне дөрес язу.

Татар телендә сүзләргә кушымчалар ялгау кагыйдәләре.

**Пунктуация.** Җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре.

# ТЕМАТИК ПЛАН

| № | Дәреснең темасы: Лексик тема | Дәреснең темасы: Грамматик тема | Сәг. саны | Белем, эш осталыгы һәм күнекмәләренә таләпләр |
|---|---|---|---|---|
| | **Мин**<br>**20/10* сәгать** | | | |
| 1 | Мәктәптә һәм өйдә | Сузык авазлар. Калын сузыклар. Нечкә сузыклар. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Текстны аңлап уку, рольләргә бүлеп уку.<br><br>Татар телендәге сузык авазларның санын белү, аларны дөрес әйтү. Калын һәм нечкә сузык авазларны аера белү.<br><br>Рус теленнән кергән сүзләрдә [о̄], [ы̄], [э̄] авазларын дөрес уку.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 6–12, 16–17 битләр. 7, 12–15 битләр. |
| | | [о̄], [ы̄], [э̄] сузыклары. | 2 | |
| 2 | Көн тәртибе | Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр. Аларга кушымчалар ялгау. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Текстны аңлап уку, сөйләү, дөрес язу. Диалогта катнашу. Башваткыч чишү. |

* Кара хәрефләр белән бирелгән материал ике юнәлешкә дә, зәңгәр төс белән бирелгәне тирәнтен өйрәнүчеләргә генә карый.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Калын сузыклар да, нечкә сузыклар да булган сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлеге. | 1 | Татар телендә сузык авазларны төркемли белү. Сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлеге белән танышу. Үзеңнең көн тәртибең турында сөйли белү. Атна көннәренең исемнәрен яттан өйрәнү.<br><br>Бер сүздә калын сузык аваз да, нечкә сузык аваз да булган очракта, кушымчаларны дөрес ялгау. Табышмакларның җавапларын табу.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 18–19, 21–27 битләр. 20, 22, 24 битләр. |
| 3 | Дус гаилә – бәхетле гаилә | [а], [о], [ы], [ө] авазлары. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Текстларны аңлап уку, сөйләү, дөрес язу, сорауларга җаваплар бирү.<br><br>Сузык авазларны дөрес әйтү. Кыска әйтелешле [а], [о], [ы], [ө]. Сузык авазлары булган сүзләрне дөрес уку һәм хатасыз язу. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | -кай/-кәй кушымчасының мәгънәсе. | 1 | Өйдә өлкәннәргә ничек ярдәм итеп булу турында әңгәмә кору.<br><br>-кай/-кәй кушымчаларын урынлы кулланa белү. Бу кушымчаның яратып, иркәләп әйткәнне белдерүен аңлау. Үзеңнең гаиләң турында сөйли белү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 28–32, 34–39 битләр. 30–31, 33–34 битләр. |
| 4 | «Кадерле бүләк» тексты белән эш | | 1 | Дәрестә тыңлаган текст белән эшләү. Сорауларга җаваплар бирү, телдән һәм язмача күнегүләр башкару, тест эшләү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 40–43 битләр. |
| 5 | Дуслар белән күңелле | Тартык авазлар. Татар теленең үзенчәлекле авазлары [w], [ғ], [қ]. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Тартык авазларны тану, дөрес уку. Татар телендәге үзенчәлекле тартыкларны белү, дөрес уку: [w], [ғ], [қ], [х], [ч]; [ж], [ң], [h]. Ике аваз белдерә торган тартык авазларны билгеләү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Татар телендә [в] авазының кулланылуы. [қ], [ғ], [к], [г] авазларының кулланылу үзенчәлекләре. | 2 | Алынма сүзләрдә [в] авазын дөрес уку. [қ], [ғ], [к], [г] авазлары кергән сүзләрне дөрес уку һәм язу.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 44–47, 50–54 битләр. 48-49, 53-54 битләр. |
| 6 | Дус яшәү серләре | Татар теленең үзенчәлекле авазлары [җ], [ң], [һ]. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Текстларны уку, аңлау, биремнәр башкару. Авазларга характеристика бирә белү (сузык — тартык, яңгырау тартык — саңгырау тартык, парлы — парсыз). Дустың турында хикәя төзеп сөйләү.<br><br>[м], [н], [ң] авазлары кергән сүзләрне дөрес уку, язу. Борын авазларына тәмамланган сүзләргә күплек кушымчасын дөрес ялгау. Сүздәге иҗекләр санын билгеләү. Дуслык турында әңгәмә кору. |
| | | Борын авазлары [м], [н], [ң]. | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br>Дәреслек, 1 кисәк: 55–60, 62, 65 битләр. 58, 61–62, 63–65 битләр. |
| 7 | Уен-дәрес «Дустым янына барам» | | 1 | Диалогларда катнашу. Дөрес язу һәм уку кагыйдәләрен искә төшерү. Юл йөрү кагыйдәләре, юлда үзеңне дөрес тоту турында әңгәмә кору.<br>Дәреслек, 1 кисәк: 66–67 битләр. |
| 8 | «Йолдыз-кай» тексты белән эш | | 1/1 | Дәрестә тыңлаган текст белән эшләү, дөрес уку, сорауларга җаваплар бирү, текстка карата сораулар төзү.<br>Диалогик һәм монологик сөйләм төрләрен дөрес билгеләү.<br>Дәреслек, 1 кисәк: 68–69 битләр. |
| 9 | Мин укырга яратам | Татар алфавиты. Сүзлекләр. | 1 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Баш һәм юл хәреф-ләрен дөрес язу. Татар алфавитын яттан белү. Текстны |
| | | Сүзлекләрнең төрләре. | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | дөрес итеп күчереп язу күнекмәләре булдыру.<br><br>Русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр белән эшләргә өйрәнү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 70–74, 77 битләр. 75-77 битләр. |
| 10 | Кабатлау | | 1 | Аудиотекстны аңлау, биремнәр башкару. Текст төзү үзенчәлекләрен, җөмләләр, текст өлешләренең тәртибен белү. Туган телнең орфоэпик кагыйдәләрен саклап, дөрес интонация белән диалогик һәм монологик сөйләм төзү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 78–79 битләр. |
| **Тирә-як, көнкүреш**<br>**11/ 5 сәгать** | | | | |
| 11 | Әкияттә кунакта | Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сүз һәм җөмләне аера булу. Сүзләрнең мәгънә үзенчәлекләрен күзәтү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Лексик мәгънәләренә карап, сүзләрне төркемләү. | 1 | Текстны аңлап уку.<br><br>Сүзләрне мәгънәләренә карап төркемли белү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 82–86, 88–90 битләр.<br>84, 86–87, 90 битләр. |
| 12 | Әкият геройлары бездә кунакта | Синоним сүзләр. Сөйләмдә синонимнарны дөрес куллану. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сүзләрнең синонимнарын табу. Мәгънәдәш сүзләрне сөйләмдә дөрес куллану. Синоним сүзләр ярдәмендә әкият геройларын тасвирлау.<br><br>Укыган текстның планын төзү. План ярдәмендә текстның эчтәлеген сөйләү. Төрле халык әкиятләренең геройларын чагыштыру.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 1 кисәк: 91–94, 99–101 битләр.<br>94, 95–98 битләр. |
| | | Синонимнар рәте. Синонимнарның әкиятләрдә кулланылуы. | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13 | Кем ялкау да кем тырыш | Антоним сүзләр Антонимнарның сөйләмдә кулланылуы. | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сүзләрнең капма-каршы мәгънәләрен билгеләү. Синонимнар һәм антонимнар ярдәмендә укыган әкиятләрнең геройларын чагыштыру. Үзең әкият язып карау. |
| | | *-лы/-ле, -сыз/-сез* кушымчалары ярдәмендә ясалган антонимнар. | 2 | *-лы/-ле* һәм *-сыз/-сез* кушымчалары ярдәмендә антоним сүзләр ясау. Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. Дәреслек, 1 кисәк: 102–104, 106–107 битләр. 103, 104, 105–106 битләр. |
| 14 | Текст белән эш | | 1 | Аудиотекстны тыңлап, телдән һәм язмача биремнәр башкару. Дәреслек, 1 кисәк: 108–110 битләр. |
| 15 | Кабатлау | | 1 | Өйрәнгән лексик, грамматик материалны кабатлау. Татар сөйләм этикеты нормаларын белү. Дәреслек, 1 кисәк: 111–113 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 16 | Бирелгән үрнәктән җөмләләрне күчереп язу | | 1 | Баш һәм юл хәрефләрен дөрес язу. Хәреф, хәреф тезмәләрен, иҗек, сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу күнекмәләре булдыру. |
| | | **Туган җирем**<br>**22/ 11 сәгать** | | |
| 17 | Әдәпле бул, сәләтле бул! | Сүз төркемнәре турында мәгълүмат бирү. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Мөстәкыйль сүз төркемнәреннән исем, сыйфат һәм фигыльне тану.<br>Сүзтезмә белән җөмләне аера белү (терминнарны атамый гына). Татар сөйләм этикеты үрнәкләрен дөрес куллану.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br>Дәреслек, 2 кисәк: 6–12, 14 битләр. 12–14 битләр. |
| | | Сүз. Сүзтезмә. Җөмлә. | 1 | |
| 18 | Тәртип кайдан башлана? | Исем сүз төркеме. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Исем сүз төркемен тану. «Тәрбияле бала нинди булырга тиеш?» темасына әңгәмәдә катнашу. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Лексик мәгънәләренә карап, исемнәрне төркемләү. | 2 | Исемнәрнең лексик мәгънәләрен билгеләү. Мәгънәләренә карап, исемнәрне төркемнәргә аеру. Кроссворд чишү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 15–17, 18–20, 23–24 битләр.<br>17–18, 20, 21–22 битләр. |
| 19 | Тамаша залында | Баш хәрефтән языла торган сүзләр. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Кеше исемнәрен, фамилияләрен, авыл, шәһәр, елга, күл, тау атамаларын дөрес язу. Җәмәгать урыннарында үзеңне дөрес тоту турында сөйләшү.<br><br>Ялгызлык исем төшенчәсе белән танышу. Рәсем ярдәмендә кечкенә текст төзү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 25–29, 33 битләр.<br>27, 29-32 битләр. |
| | | Ялгызлык исемнәр. | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20 | Бирелгән үрнәктән җөмләләрне күчереп язу | | 1 | Баш һәм юл хәрефләрен дөрес язу. Хәреф, хәреф тезмәләрен, иҗек, сүз һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу күнекмәләре булдыру. |
| 21 | Зоопаркта | Күплек сан. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Исемнәрнең күплек санын ясау. Күплек сандагы исемнәрне сөйләмдә дөрес куллану. Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү күнекмәләре булдыру.<br><br>Рус һәм татар телендәге сан категориясен чагыштыру. Рус телендә күплек санда гына кулланыла торган сүзләрне искә төшерү. Аларның татар телендә кулланылу үзенчәлекләре белән танышу (сәгать, сәгатьләр, күзлек, күзлекләр) Табышмаклар чишү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. |
| | | Рус телендә күплек саны гына булган сүзләрне татар телендә куллану. | 2 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Дәреслек, 2 кисәк: 34–38, 41, 43 битләр. 36–37, 38–40, 42 битләр. |
| 22 | Изложение | | 1 | |
| 23 | Агачлар — безнең яшел дусларыбыз. | Сыйфат сүз төркеме. | 2 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сыйфат сүз төркемен тану, аңа хас грамматик категорияләрне билгеләү. Агач, кош атамаларын белү.<br><br>Сыйфатлар ярдәмендә исемнәрнең кайсы билгеләре ачыклануын аңлау. Кушымчалар ярдәмендә исемнәрдән сыйфатлар ясау.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. Дәреслек, 2 кисәк: 44–45, 47–51 битләр. 46, 49, 51 битләр. |
| | | Сыйфатларның сөйләмдә кулланылышы. | 2 | |
| 24 | Иҗади эш | | 1 | |
| 25 | Кабатлау | | 1/1 | Өйрәнгән грамматик һәм лексик материалны кабатлау. Татар сөйләм этикеты нормаларын белү. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 26 | Дүрт аяклы дусларым | Хәзерге заман хикәя фигыль.<br><br>*-ла/-лә* кушымчасы ярдәмендә фигыль ясалу. | 1<br><br>1 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Хәзерге заман хикәя фигыль формасын белү. Аларны сөйләмдә дөрес куллану.<br><br>Исемнәргә *-ла/-лә* кушымчасы ялгап, фигыльләр ясау. Йорт хайваннары турында әңгәмә кору.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. Дәреслек, 2 кисәк: 54–58 битләр. 58–60 битләр. |
| 27 | «Начарлык» тексты белән эш. | | 1/1 | Аудиотекстны тыңлап аңлау. Телдән һәм язмача күнегүләр эшләү.<br><br>«Әби белән онык» тексты белән эшләү.<br><br>Дәреслек, 2 кисәк: 61–65 битләр. |
| 28 | Диктант | | 1 | |
| 29 | Контроль эш | | 1 | |
| | | **Татар дөньясы**<br>**15/ 8 сәгать** | | |
| 30 | Бөтен эшне бергә эшлибез | Сүз һәм җөмлә. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Сүзнең лексик |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Җөмләдә фигыльнең урыны. | 2 | мәгънәсен билгеләү. Җөмләнең беренче сүзен баш хәрефтән язу. «Май чабу» бәйрәме турында диалогта катнашу.<br>Гади җөмләдә сүзләрнең урнашу тәртибен белү. Дөрес итеп җөмләләр төзү. Текстны үзлектән укып, аны аңлау, биремнәр башкару.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. Дәреслек, 2 кисәк: 68–73 битләр. 72–73 битләр. |
| 31 | Язны каршылыйбыз. | Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләре.<br>Интонация. | 3<br>1 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Әйтелү максаты ягыннан җөмлә төрләрен дөрес билгеләү. Җөмлә ахырында тиешле тыныш билгесен куя белү.<br>Хикәя, сорау һәм тойгылы җөмләләрне дөрес интонация белән уку. Тексттан кирәкле мәгълүматны таба белү.<br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. Дәреслек, 2 кисәк: 74–76, 78 битләр. 76, 77–78 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 32 | Язгы яңа ел | Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. | 3 | Уку бурычын дөрес билгеләү. Хикәя, сорау, тойгылы җөмләләрне тану. Җөмлә ахырында нокта, өтер, өндәү билгесен дөрес куллану. «Нәүруз» темасына парларда эш. |
| | | Стиль хаталары: кабатлаулар. | 2 | Кабатлаулардан котылу өчен, җөмләдә сүзләрне синонимнары, алмашлыклар белән алыштыра белү. Рәсем ярдәмендә диалог төзү. Сөйләм хаталарын табу һәм төзәтү.<br><br>Үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәсенә бәя бирү. Дәреслек, 2 кисәк: 79–82, 84 битләр. 82–83 битләр. |
| 33 | Сүзлек диктанты | | 1 | |
| 34 | «Кечкенә Апуш Сабантуйда» тексты белән эш | | 1/1 | Текстны уку, язмача һәм телдән күнегүләр эшләү. Дәреслек, 2 кисәк: 85–87 битләр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 35 | Кабатлау | | 1/1 | Алдагы дәресләрдә өйрәнгән грамматик, лексик материалны кабатлау. Үзлектән текстны уку. Тексттан кирәкле мәгълүматны табу. Дәреслек, 2 кисәк: 88–92 битләр. |
| | Җөмләләр белән эшләү: бирелгән сүзләрдән җөмләләр төзү. | | 1 | Дөрес итеп җөмләләр төзү. Бирелгән җөмләләрдән, абзацлардан текст төзү. Җөмләләрнең баш кисәкләрен билгеләү. |
| | 2 класста өйрәнгән-нәрне кабатлау | | 1/1 | Аудиотекстны тыңлап аңлау. Ел дәвамында өйрәнгән лексик, грамматик материалны кабатлау, ныгыту. Дәреслек, 2 кисәк: 93–99 битләр. |
| | Контроль күчереп язу | | 1 | Өйрәнгән дөрес язу кагыйдәләрен куллану. Сүзләрне һәм җөмләләрне дөрес күчереп язу. |

# ДӘРЕС ПЛАННАРЫ ҮРНӘКЛӘРЕ

**Лексик тема: Мәктәптә һәм өйдә**
**3 / 2* сәгать**
**1 дәрес**

**Тема: Сузык авазлар**

**Максат һәм бурычлар:** укучыларны быелгы уку елына куелган максат һәм бурычлар, дәреслек һәм аның үзенчәлекләре, шартлы билгеләр белән таныштыру; «Мәктәп һәм өй» темасы белән бәйләп, сөйләмә һәм язма телне үстерү, татар телендәге сузык авазларның санын белү, аларны дөрес әйтү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

**Дәрес этаплары**

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Дәреслекнең 6 битендәге 1 күнегүне эшләү (сораулар һәм җаваплар).

2) Сузык авазлар турында әңгәмә.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1) Татар телендә сузык авазлар һәм аларның саны.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Әби, Илнур һәм шигырь» тексты белән эшләү (8 бит, 3 күнегү).

2) Таблица белән эш (9 бит).

3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

4) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

---

* База өлешен өйрәнүчеләр өчен дәрес үрнәкләре кара хәрефләр белән, тирәнтен өйрәнүчеләргә караган материал зәңгәр хәрефләр белән бирелде.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 2 дәрес

**Тема:** **Калын сузыклар**

**Максат һәм бурычлар:** мәктәп һәм өй турында сөйләшүне дәвам итеп, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү, калын сузык авазлар турында мәгълүмат бирү һәм ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: калын сузыклар.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

Калын сузыклар һәм аларның әйтелеше.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Буламы мондый бала?» шигыре белән эшләү (10 бит).
2) Рәсемнәр белән эш (11 бит).
3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
4) 5 нче күнегү (11 бит).
5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 3 дәрес

**Тема:** **Нечкә сузыклар**

**Максат һәм бурычлар:** өй һәм мәктәп турында сөйләшүне дәвам итү; калын һәм нечкә сузык авазларны аера белү.

**Дәрес тибы: рефлексия дәресе (катнаш дәрес).**

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: калын һәм нечкә сузыклар.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

Парлы һәм парсыз сузыклар.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Рольләргә бүлеп уку (12 бит).
2) 9, 10 нчы күнегүләр белән эш (16, 17 битләр)
3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
4) Рәсемле башваткычны чишү (17 бит).
5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 4 дәрес

**Тема:** **[$\bar{о}$], [$\bar{ы}$], [$\bar{э}$] сузыклары**

**Максат һәм бурычлар:** мәктәп һәм өй турында сөйләшүне дәвам итеп, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү, [$\bar{о}$], [$\bar{ы}$], [$\bar{э}$] сузыклары турында мәгълүмат бирү һәм ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

## Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: [о̄], [ы̄], [э̄] сузыклары.

3. Уку мәсьәләсе кую.

Рус теленнән кергән сүзләрдә [о̄], [ы̄], [э̄] сузыкларын дөрес уку.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Юкка малай булганмын» шигыре белән эш (7 бит).
2) Рольләргә бүлеп уку (12 бит).
3) 6 нчы күнегү белән эш (13 бит).
4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 5 дәрес

**Максат һәм бурычлар:** мәктәп һәм өй турында сөйләшү, укучыларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү, [о̄], [ы̄], [э̄] сузыклары турында мәгълүматны ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек

## Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: [о̄], [ы̄], [э̄] сузыклары.

3. Уку мәсьәләсе кую.

Татар һәм рус телләрендәге [о], [ы], [э] сузыкларын чагыштыру.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) «Тәмле тамаклар» шигыре белән эш (14–15 битләр).

2) Табышмакларның җавабын табу (15 бит).

3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

4) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

**Лексик тема: Көн тәртибе**
**3 / 1 сәгать**
**6 дәрес**

**Тема: Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр**

**Максат һәм бурычлар:** атна көннәренең исемнәрен яттан өйрәнү, калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр турында мәгълүмат бирү һәм ныгыту.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

### Д ә р е с   э т а п л а р ы

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.
2) Әңгәмә: калын һәм нечкә сузыклар.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1. Татар телендә сузык авазларны төркемләү.
2. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) 12 күнегү белән эшләү (18 бит).
2) 13 күнегү белән эш (19 бит).
3) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.
4) 15 нче күнегү (21 бит).
5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.
2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.
3) Өй эше.
4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 7 дәрес

**Тема: Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә кушымчалар ялгау**

**Максат һәм бурычлар:** үзеңнең көн тәртибең турында сөйли белү, калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә кушымчалар ялгарга өйрәтү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

## Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: калын һәм нечкә әйтелешле сүзләр.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1. Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә кушымчалар ялгау тәртибе

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) Рольләргә бүлеп уку (22 бит).

2) «Бер атнада ничә көн?» шигыре белән эш (16 күнегү, 23–24 битләр).

3) 22 күнегү белән зш (27 бит).

4) Дәреслекнең сүзлекчәсе белән эш.

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 8 дәрес

**Тема: Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә кушымчалар ялгау тәртибе**

**Максат һәм бурычлар:** көн тәртибе турында фикер алышуны дәвам итү, уку бурычын дөрес билгеләү, текстны аңлап уку, сөйләү һәм дөрес язу; диалогта катнашу, калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә кушымчалар ялгау тәртибен өйрәтү.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

## Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә кушымчалар ялгау.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1. Сүзләргә кушымчалар ялгау тәртибе.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) 18 күнегү белән эш (25 бит).

2) Таблица белән эш (19 күнегү, 25 бит).

3) «Кунакка килегез!» шигыре белән эш (20 күнегү, 26 бит).

4) 21 күнегү белән эш (27 бит).

5) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

## 9 дәрес

**Тема: Калын сузыклар да, нечкә сузыклар да булган сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлеге**

**Максат һәм бурычлар:** татар телендә сузык авазларны төркемли белү, сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлеге белән танышу.

**Дәрес тибы:** рефлексия дәресе (катнаш дәрес).

**Җиһазлау:** электрон дәреслек.

## Дәрес этаплары

**I. Мотивлаштыру-ориентлаштыру.**

***1. Дәресне оештыру.***

Исәнләшү, укучыларның хәлләрен сорашу, психологик уңай халәт тудыру.

***2. Актуальләштерү.***

1) Өй эшен тикшерү.

2) Әңгәмә: калын һәм нечкә әйтелешле сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлеге.

***3. Уку мәсьәләсе кую.***

1. Сүзләргә кушымчалар ялгау үзенчәлеге.

**II. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.**

1) 14 күнегү белән эш (20 бит).

2) Рольләргә бүлеп уку (22 бит).

3) Табышмакларның җавабын әйтү (17 күнегү, 24 бит).

4) Нәтиҗәләр чыгару.

**III. Рефлексив бәяләү.**

1) Рефлексив кабатлау.

2) Дәрескә гомуми бәя. Һәр укучының үз эшчәнлеген бәяләве.

3) Өй эше.

4) Алдагы дәрескә проблема кую.

Учебное издание

**Шакурова** Муслима Магесумовна
**Гиниятуллина** Лилия Миннулловна
**Хисамов** Олег Ришатович

**РОДНОЙ ЯЗЫК**
**(татарский язык)**

2 класс

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
начального общего образования
(для изучающих татарский язык как родной)

*Допущено Министерством образования и науки*
*Республики Татарстан*

Казань. Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова. 2020
*На татарском языке*

Уку-укыту басмасы

**Шәкүрова** Мөслимә Мәгъсүм кызы
**Гыйниятуллина** Лилия Миңнулла кызы
**Хисамов** Олег Ришат улы

**ТУГАН ТЕЛ**
**(татар теле)**

2 сыйныф

Методик әсбап
башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
(татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән)
эшләүче укытучылар өчен

*Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән*
*министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән*

Художник *А. Б. Шляпкин*
Верстка *Э. Ф. Нурмухаметовой*

Подписано в печать с оригинал-макета 20.04.2020.
Формат 60 x 84 1/16.